ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» 06 2021 ел № 158

**«Балтач муниципаль районының шәһәр тибындагы поселогында һәм авыл җирлегендә эшләүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2017 елның 22 апрелендәге 82 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы **карар бирә:**

1. «Балтач муниципаль районының шәһәр тибындагы поселогында һәм авыл җирлегендә эшләүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2017 елның 22 апрелендәге 82 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карарына (2017 елның 7 сентябрендәге 148 номерлы, 2020 елның 29 сентябрендәге 192 номерлы, 2021 елның 12 февралендәге 54 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач шәһәр тибындагы поселогында һәм Балтач муниципаль районының авыл җирлегендә эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр белгечләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтүне түбәндәгечә билгеләргә:

мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсе муниципаль учреждениеләре, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү муниципаль системасының социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре хезмәткәрләренә - Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән торак мәйданының социаль нормасы һәм коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативлары чикләрендә торак өчен түләү, җылылык, яктырту чыгымнарының 100 проценты күләмендә. Шулай ук күрсәтелгән социаль ярдәм чарасы авыл җирендә яшәүче һәм авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләрендә, Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләгән күрсәтелгән хезмәткәрләр арасыннан пенсиягә чыккан, 60 һәм 55 яшькә җиткән гражданнарга (тиешенчә

ир-атлар һәм хатын-кызлар), шулай ук 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килгән, әмма 60 һәм 55 яшькә җитмәгән (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) гражданнарга бирелә.»;

1.2. 1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче абзацны өстәргә:

«Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә күрсәтелгән бурыч җайга салынганда, социаль ярдәм чараларын күрсәтү аларны билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән көннән гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль
районы башлыгы Р. Р. Нотфуллин